# *Касыйм Хәсән улы Ситдиков*

Касыйм Хәсән улы Ситдиков 1913 нче елда Мөслим авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Яшьли ятимлек газаплары татырга туры килә. 1915 нче елда каты авырудан соң әнисе үлә. 1918 нче елда әтисе Хәсән абзый да гражданнар сугышына алынып хәбәрсез югала. Шулай итеп 5 яшендә нәни Касыйм бөтенләй ятим кала. Әбисе, бабасы да үлгәч, апасында тәрбияләнә. Билгеле апасы белән абыйсы нәни Касыймны мөмкин кадәр яхшылап карарга, тәрбияләргә тырышканнар. 1922 нче елда 9 яшьлек Касыймны Лотфулла Сафиуллинга малайлыкка биргәннәр. Лотфулла абзыйда яшәгәндә Касыйм укый, сабак ала, аның күзе “ачыла”, тормыш барышын аңлый башлый. Лотфулла абзыйларда 18 ай торганнан соң, Лотфулла абзыйның үзенең ирбаласы дөньяга килә, бу гаиләдә Касыймга урын тарая – аны кыерсыта башлыйлар. Озак үтми, җизнәсе Насыйбулла белән апасы Зарифә Касыймны үзләренең тәрбиясенә алалар, башлангыч мәктәпкә укырга бирәләр. Укырга китабы, язарга дәфтәре булмау да Касыймга яхшы укырга комачаулык итә алмаган. Ул 4 классны бик яхшы билгеләргә генә тәмамлый.

1930 нчы елда К.Ситдиков “5” ле билгеләренә генә укуы өчен, мәктәп тарафыннан, Чистай педагогия техникумына укырга җибәрелә. Үзенең яхшы укуы, тәртибе, җәмагать эшләрендә актив катнашуы белән, К.Ситдиков техникум укытучылары һәм студентлары арасында тиз арада зур авторитет яулый. Җәйге каникуллар вакытында техникумның ярдәмче хуҗалыгында эшли, спорт белән шөгыльләнә.

Чистай педагогия техникумын уңышлы тәмамлаганнан соң, 1934 нче елның августында, К.Ситдиков Шахмай авылы мәктәбенә укытучы итеп эшкә җибәрелә. Яшь педагогны укучылар бик яраталар, тиз арада ата-аналар тарафыннан хөрмәт казана. 1935-1937 елларда Касыйм Ситдыйков Кызыл Армия сафларында хезмәт итә. Армиядән кайтканнан соң К.Ситдыйков Дүрт Өйле җидееллык мәктәбенә уку-укыту эшләре бүлеге мөдире итеп билгеләнә, бер үк вакытта ул мәктәптә география, рәсем һәм физкультура дәресләрен алып бара. Аның элеккеге укучылары зур хөрмәт белән искә алалар.

-Без барыбыз да Касыйм абыйны ярата идек. Ул дәресләрне бик яхшы итеп оештыра иде, күңелле итеп үткәрә иде. Тәнәфес вакытында гармунда уйный, безне биергә өйрәтә иде. Ул безнең хәтердә кеше- лекле һәм киң күңелле булып истә калды. Мәктәптә гармун тавышы ишетсәм, хәзер дә күземә яшьләр килә,-дип искә ала Зәкия апа. Дүрт Өйледә эшләгәндә Касыйм Ситдиков ата-аналар һәм авыл халкы арасында зур эш җәелдерә: клубта колхозчыларның ялларын күңелле оештыруда актив катнаша, докладлар укый, спектакльләр уйный. Шул чорда авыл советы рәисе булып эшләгән Галимов болай ди: “Иптәш Ситдиковның оештыру сәләте бик зур иде. Кешенең йөрәгенә кереп сөйләшә белүе, халыкның ихтыяҗларын тиз аңлавы, кешегә ярдәмчел булуы, политзанятиеләрне оста үткәрә алуы белән ул халык арасында үзен тиз күрсәтә алды. Бөтен эшне дә без бергәләп эшли идек. Авыл советының ышанычлы ярдәмчесе, һәрвакыт ачык йөзле, житез, хәрәкәтчән, бик энергияле кеше иде”.

Ил өстендә сугыш болытлары куера башлый. Шунлыктан Касыйм Ситдиков Эстониядәге хәрби частькә хәзерлек үтү өчен чакырыла. Бөек Ватан сугышын ул шунда каршылый. Сугышның беренче көненнән үк безнең якташыбыз немец басып алучылары белән каты бәрелешләрдә катнаша. Коммунист, командир буларак үз подразделениесен дошманга каршы атакага оста итеп алып бара. Дошманның җанлы көчләрен, техникасын җитди югалтуларга дучар итә. Үткен сүзе, шәхси үрнәк күрсәтүе белән сугышчыларны җиңүгә рухландыра.

Ватаныбызның азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен барган изге көрәш кырларында ул 5 тапкыр яралана. Госпитальләрдә дәваланып чыкканнан соң фронтның алгы сызыгына кайта.

Сугышчан хезмәтләре өчен Касыйм Ситдиков Кызыл Байрак һәм 1 нче дәрәҗә Ватан

сугышы ордены һәм күп кенә медальләр белән бүләкләнә.

1944 нче елның октябрь аенда совет гаскәрләре Венгрия территориясен немец — фашист оккупантларын азат итү миссиясен башлыйлар. Капитан К. Ситдыйков Венгрия территориясендә барган сугышларның башыннан алып ахырына кадәр катнаша. Соңгы хатларының берсендә болай дип яза: “Сания, сугыш көчле бара, корбансыз булмас. Хәзер безнең гаскәрләребез шәһәребезне немец илбасарларыннан азат итә. Дошманны куып барабыз. Менә без Венгрия җирендә. Син борчылма, Луиза белән Эльза кызларымның күңелләре боекмасын. Без барыбер дошманны җиңәрбез!”

Дүрт елга якын сугыш дәвамында Касыйм Ситдыйков күпне күрә, күпне кичерә. Ләкин Венгриянең Балатон күле районындагы кебек дәһшәтле сугышны беренче очрата. Аның батальоны һәркөнне берничәшәр атакага бара. Совет Армиясенең Балатон, Веленце күлләре янында урнашкан девизия частьләренә каршы немецлар йөзләрчә танк җибәрәләр. Дошман бернинди югалтулар белән дә санашмыйча, котырынып алга омтыла.

1945 нче елның 13 мартында Тюкреш хуторы өчен барган каты сугышларда капитан Касыйм Ситдыйков команда пунктын ташлап командирын югалткан 4 нче рота белән җитәкли башлый. Аның җитәкчелегендә рота пулеметчылары танклары артыннан баручы немец автоматчыларына җимергеч удар ясап, аларны чигенергә мәҗбүр итә. Бер сәгать тә үтми, яңа атака башлана. Капитан Ситдыйков авырлыкның якынлашуын, сугышның барышын һәм кешеләрнең язмышын хәл итүче минутларның килеп җитүен сизә. Яндыргыч бутылкалар алып дошманга каршы ташлана. Ату тавышлары астыннан аның:

-Туган ил өчен! Җиңү өчен ! - дигән сүзләре генә бүленеп-бүленеп ишетелеп кала. Гомерен кызганмыйча 3 танкка каршы чыга, ике танкны яндыра, үзе бик каты яралана. Солдатлар үзләренең сөекле командирларын окопка алып төшәләр, яраларын бәйлиләр. Ситдыйков окоптан торып сугыш белән җитәкчелек итә,соңгы сулышына кадәр сугыша һәм геройларча һәлак була...

Командованиенең сугышчан заданиесен үрнәк булырлык итеп үтәгәне өчен капитан Касыйм Хәсән улы Ситдыйковка СССР Верховный Советы президиумының 1945 нче елның 20 нче июль Указы белән Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

1963 елның 4 ноябрендә авылыбызның уртасында Советлар Союзы Герое К.Ситдыйковка бюст куела.